СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.12.2021 Баулы шәһәре № 96

Баулы муниципаль районы Советының
2018 елның 3 июлендәге «Татарстан
Республикасы «Баулы муниципаль районы»
муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны
(иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру
һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне
раслау хакында» 160 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 3 июлендәге «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 160 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 статья. Ачык тыңлаулар инициаторлары:

Ачык тыңлаулар халык, Баулы район Советы (алга таба - Совет), Баулы муниципаль районы Башлыгы (алга таба - Башлык), үз вәкаләтләрен контракт нигезендә башкаручы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - Башкарма комитет җитәкчесе) инициативасы белән Регламент нигезендә үткәрелә.»;

5 статьяның 1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район башлыгы яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Башкарма комитет җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар Баулы муниципаль районы башлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

6 статьяның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилләп нигезләүне дә кертеп, массакүләм мәгълүмат чараларында, Баулы муниципаль районы сайтында һәм (яисә) башка мәгълүмат системаларында һәм мәгълүмат стендларында бастырыла (халыкка җиткерелә).»;

12 статьяның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлекләрнең генераль планнары, шәһәр округларының генераль планнары проектлары һәм җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар (алга таба - иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3.1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында уздырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы, район Советы
Рәисе вазыйфаларын башкаручы –
район башлыгы урынбасары, Советы
Рәисе урынбасары — Р.Г. Хәмидуллин